Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Оешмалар мөлкәтенә салым турында" Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Оешмалар мөлкәтенә салым турында" 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2004, № 3 (I өлеш), № 4 – 5, № 10, № 11; 2005, № 7 – 8, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (II өлеш); 2008, № 5 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2009, № 6, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 11 май) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

"16) Казан шәһәрендә уздырылачак 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын оештыручы коммерциягә карамаган автоном оешмалар.";

б) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

"4) оешмалар мөлкәтенә – федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалардан тыш, мәдәният һәм сәнгать, мәгариф, физик культура һәм спорт, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү ихтыяҗлары өчен файдаланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата.";

2) 5 статьяда:

а) 1 пунктта "3 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктын, 2 өлешендәге 2 – 6 пунктларын, 3 өлешен" сүзләрен "3 статьясындагы 1 өлешенең 3, 11 – 13

пунктларын, 2 өлешенең 6 пунктын, 3 өлешенең 3 пунктын" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта "1 өлешенең 11 – 15 пунктларын, 2 өлешенең 7 пунктын" сүзләрен "1 өлешенең 14, 15 пунктларын" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 һәм 6 пунктлар өстәргә:

"5) 2014 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 16 пунктын;

6) 2015 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктын, 2 өлешенең 2 – 5, 7 пунктларын, 3 өлешенең 1, 2, 4 пунктларын.".

**2 статья**

Әлеге Закон 2012 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да алданрак булмаган вакытта, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 57-ТРЗ